**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.05.2017 г.Казань № 01-02/42

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә белергә ярый торган мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматларны урнаштыра торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайт битләре адреслары турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 20.2 статьясы, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3–ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17.2 статьясы нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә белергә ярый торган мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштыра торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайт битләре адреслары турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерүнең әлеге тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамагымда калдырам.

Министр Л.Ю. Глухова

Татарстан Республикасы
юстиция министрының
16.05.2017 № 01-02/42
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә белергә ярый торган мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштыра торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайт битләре адреслары турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә белергә ярый торган мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштыра торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайт битләре адреслары турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) билгели:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның (алга таба – гражданин) һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәре, Министрлык) һәркемгә белергә ярый торган мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштыра торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайт битләре адреслары (алга таба – Сайтлар турында мәгълүматлар, «Интернет» челтәре) турындагы мәгълүматны тапшыру кагыйдәләрен;

Сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибен.

2. «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә һәркемгә белергә ярый торган мәгълүмат дигәндә аларга керү чикләнмәгән гомумбилгеле мәгълүматлар һәм башка мәгълүматлар аңлашыла. Монда мәгълүматны белүгә чикләүләр булмау чикләнмәгән сандагы кешеләргә урнаштырылган мәгълүматны граждан хезмәткәренең яки гражданинның рөхсәтеннән башка алу һәм үзе теләгәнчә файдалану мөмкинлеген күздә тота.

3. Граждан хезмәткәрен яки гражданны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар сыйфатында түбәндәге мәгълүматлар: фамилия һәм исем, фотосурәт, эш урыны турындагы мәгълүматлар җыелмасы яки шулардан берсе дә торырга мөмкин.

## II. Сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында мәгълүматларны тапшыралар:

гражданин – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) кергәндә граждан хезмәтенә кергәнгә кадәрге өч ел өчен;

граждан хезмәткәре – алдагы календарь ел өчен ел саен хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча.

5. Сайтлар турында мәгълүматлар гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форма (алга таба – Форма) нигезендә тапшырылалар.

6. Һәркемгә белергә ярый торган мәгълүмат, әгәр дә ул граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәве кысаларында урнаштырылган булса, Формада чагылдырылырга тиеш түгел.

7. Тутырылган Форма граждан хезмәткәре яки гражданин тарафыннан кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең Татарстан Республикасы юстиция министры боерыгы белән Сайтлар турында мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләнгән хезмәткәренә (алга таба – җаваплы зат) тапшырыла.

8. Җаваплы зат Форманың тутырылу тулылыгын, «Интернет» челтәреннән файдаланып анда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерә, имзасын куя, мәгълүматларны Форма алынган көнне әлеге Тәртипкә Кушымта нигезендәге форма буенча журналга кертә.

9. Тутырылмаган полялары булган Форма кабул ителми.

10. Гражданин тарафыннан бирелгән Формада дөреслеккә туры килми торган мәгълүматлар булуы ачыкланган очракта кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге кичекмәстән аны граждан хезмәте вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында белдерә.

11. Сайтлар турында мәгълүматлар җаваплы зат тарафыннан граждан хезмәткәрләренең «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси карточкаларына кертелә.

12. Граждан хезмәткәрләре һәм гражданнар тарафыннан тапшырылган Формалар кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегендә биш ел дәвамында саклана, аннан соң Министрлыкта Персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре белән билгеләгән тәртиптә юкка чыгарылалар.

## III. Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Сайтлар турында граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган

мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү министр (министр вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Тикшерү өчен түбәндәгеләр тарафыннан язма рәвештә тапшырылган мәгълүмат җитәрлек нигез булып тора:

хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан;

сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкче органнарыннан һәм сәяси партияләр булмаган, закон нигезендә теркәлгән башка гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан.

15. Җаваплы зат граждан хезмәткәренә аңа мөнәсәбәттә тикшерү башлануы турында тикшерү уздыру турында боерык чыккан көннән ике эш көне эчендә язма рәвештә белдерә.

16. Граждан хезмәткәре тарафыннан бирелгән Сайтлар турындагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү җаваплы зат тарафыннан аның «Интернет» челтәрендә урнаштырылган һәркем белергә ярый торган мәгълүматларын эзләү һәм күрсәтелгән мәгълүматларның электрон күчермәләрен (скриншотларын) алу юлы белән башкарыла.

17. Граждан хезмәткәре тикшерү барышында һәм аның нәтиҗәләре буенча язма рәвештә аңлатмалар бирергә, өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

18. Әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына теркәләләр.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында җыелган мәгълүматлар тикшерү уздыру турында боерык чыккан көннән 10 эш көненнән артып китмәгән вакыт эчендә министрга тапшырылалар.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көнлек срокта министр карар кабул итә:

граждан хезмәткәренә юридик җаваплылык чараларын куллану өчен нигезләр булмавы турында;

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

хокук бозу, җинаятьчелек, экстремистлык эшчәнлегенә катнашы булу билгеләре табылган очракта тикшерү материалларын аларның компетенцияләре буенча дәүләт органнарына юллау турында.

21. Министр тарафыннан кабул ителгән карар турында җаваплы зат аңа мөнәсәбәттә тикшерү уздырылган граждан хезмәткәренә ике эш көне эчендә язма рәвештә белдерә.

22. Сайтлар турында мәгълүматлар министрның язма ризалыгы белән бер үк вакытта аңа мөнәсәбәттә тикшерү уздырылган граждан хезмәткәренә белдерелеп, шәхси мәгълүматлар һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарына каршы килмичә, тикшерү уздыру өчен нигез булып торган хокук саклау органнарына, сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкче органнарына һәм сәяси партияләр булмаган, закон нигезендә теркәлгән башка гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләренә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый

палатасына, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына да тапшырылырга мөмкиннәр.

23. Тикшерү материаллары кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегендә өч ел дәвамында сакла632налар, аннан соң архивка тапшырылалар.

## IV. Сайтлар турында мәгълүматларны бирмәгән өчен җаваплылык

24. Сайтлар турында мәгълүматларны бирмәгән очракта гражданин граждан хезмәтенә кабул ителә алмый, ә граждан хезмәткәре граждан хезмәтендә кала алмый.

25. Граждан хезмәткәренең Сайтлар турында мәгълүматларны бирмәве үз артыннан граждан хезмәтеннән азат ителүне ияртә торган хокук бозу очрагы булып тора.

Татарстан Республикасы юстиция министрының
______________ № ________
боерыгы белән расланган
Тәртипкә кушымта

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә белергә ярый торган мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштыра торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайт битләре адреслары турындагы мәгълүматларны теркәү журналы

| № п/п | Форманы тапшыру /кабул итү датасы | Форманы тапшыручының ФИӘ.и. | Форманы тапшыручының вазыйфасы (гражданин дәгъва белдерә торган вазыйфа) | Форманы тапшыручының имзасы (яки форма почта аша килгәндә теркәлү саны номеры) | Форманы кабул итүче затның ФИӘ.и. | Форманы кабул итүче затның имзасы | Тикшерү турында мәгълүмат (боерык реквизитлары, тикшерү нәтиҗәсе) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |